РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БОЛЬШЕШИНАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422054, Республика Татарстан,
Сабинский район,с.Большой Шинар,
ул. Кооперативная,дом 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422054, Татарстан Республикасы,
Саба районы,Олы Шыңар авылы,
Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР
13.11.2024 №26

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 2018 нче елның
30нчы апрелендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге
җирле үзидарә органнарының депутатларына,
сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль
хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары
турында Нигезләмә " турында 9нчы номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында»

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 елгы 182нче номерлы "Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, рәисләрнең, рәис урынбасарларының, муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-исәп аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" карарына үзгәрешләр турында" 25.09.2024 ел 829нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 30.04.2018 елда 9нчы номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә" карарына»( Советның 09.11.2020 ел, № 12, 17.10.2022 ел №15, 19.12.2022 №20, 23.08.2024 №14 карарлары редакциясендә ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:
«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече теркеме белгече вазифа окладын 13990 сум күләмендә расларга.»;

1.2. 1нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә, әлеге карар өчен 1нче кушымта нигезендә җиткерергә.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә

алып, 2025 елның 1 январеннан гамәлдә булу башлангач, яңа штат расписаниеләрен расларга.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү, тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

5. Әлеге карар 2025нче елның 1 январеннан үз көченә керә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru һәмТатарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ shinar адреслары буенча бастырып чыгарырга.

7. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Олы Шыңар авыл җирлеге Советының
2024елның 23нче августы,
14нче номерлы карарына
1 нче кушымта

Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының акчалата бүләкләре күләме

| Вазыйфалар исемнәре акчалата бүләк күләме (сумнарда) | акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 19 173 |
| Депутатлар | 13 990 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 13 990 |